БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
19 март 2024 ел

**КАРАР**
№ 243

**Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2021 елның 08 ноябрендәге 79 номерлы карары белән расланган муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегенә 6,7,8,9 пунктларын өстәп, үзгәреш кертергә, түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«6. Җир кишәрлегендә туфракның уңдырышлы катламын төшерү һәм (яисә) күчерү өчен кулланыла торган махсуслаштырылган техника булу.

7. Җир кишәрлегендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең торышына һәм туфракның уңдырышлылык дәрәҗәсенә йогынты ясый торган тискәре процесс билгеләре (су һәм җил эрозиясе, көчле балчык ташкыннары, су басу, сазлыкка әйләнү, туфрак тозлану, кибү, тыгызлану, химик матдәләр, шул исәптән радиоактив, башка матдәләр һәм микроорганизмнар белән пычрану, җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрану).

8. Күпьеллык җиләк-җимеш үсентеләре булмаган чүп үләннәренең һәм (яисә) агач-куак үсентеләренең үсүе,(мелиорация саклагыч урман үсентеләреннән тыш), авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен аны кулланмау яисә авыл хуҗалыгы белән бәйле башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру ачык чагылган җир кишәрлеге .

9. Җир кишәрлегендә мелиорация системасының яисә аерым урнашкан гидротехник корылманың (каналдан су чыгуы яисә мелиорация системасына керә торган яки аерым урнашкан гидротехник корылманың) зарарлануын яисә юкка чыгуын раслый торган билгеләрнең булуы; мелиорация системасы яисә аерым урнашкан гидротехник корылма булган җир кишәрлеген сазлыкка әйләндерү; шулай ук урман полосаларын тәшкил итә торган мелиоратив саклагыч урман утыртмаларын зарарлау (саклагыч урман полосаларына керүче

агач-куак үсентеләрен кисеп ташлау, өеп кую яки яндыру).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин